**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күлле-Киме авыл җирлеге Ары торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

"15" ноябрь 2022 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №109 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Ары торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары авылы территориясендә 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Ары торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш 700 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Ары урамнарын кардан чистарту, үләннәрне чабу
- иске агачларны кисү һәм чүп-чар чыгару
- урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү һәм яктырткычлар алу
- зират коймасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу
- Ары авылы юлларын ремонтлау вак таш алу һәм җәю, транспорт хезмәтләре күрсәтү
- янгын сүндерү гидрантларына ослек сатып алу һәм урнаштыру
- кое ремонтлау

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенең Ары авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күлле-Киме авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гәрәев Х.Х.